**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлеге Югары Шепкә торак пунктында гражданнар жыены карары**

**22.12.2021** **№1**

«РоссияФедерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлегенең Югары Шепкә торак пунктында гражданнар жыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлегенең Югары Шепкә авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге жирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

-балалар уен мәйданчыгына сатып алу ;

- торак пункт эчендәге юлларны өлешчә ремонтлау һәм вак таш жәю;

-Сабантуй урынын тозеклэндерү өчен материаллар сатып алу.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл жирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлегекарарны Татарстан Республикасымуниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен жибәрергә.

Югары Шепкә
авыл жирлеге башлыгы____________________ Камалиева Л.М.